**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№661**
**13.02.2020**

«Татар малае», «Татар кызы»
(мәктәпкәчә яшьтәге балалар)
муниципаль конкурсын
оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте программасын тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә 2020 елның 18 мартыннан 2020 елның 17 апреленә кадәр «Татар малае», «Татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар) муниципаль конкурсын (алга таба - конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 70 000,00 (җитмеш мең) сум 00 тиен күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                                                  И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 13 февралендәге
661 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татар малае», «Татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар)
муниципаль конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татар малае», «Татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар) муниципаль конкурсы (алга таба - конкурс) яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, конкурста катнашучыларның башкару осталыгын күтәрү максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү;

2) балаларның игътибарын татар халкының рухи традицияләренә җәлеп итү;

3) мәктәпкәчә яшьтәге балаларның татар телендә иркен аралашу дәрәҗәсен күтәрү;

4) балаларны театр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләренә җәлеп итү;

5) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә (алга таба - МББУ) балаларның иҗади потенциалын үстерүгә шартлар булдыру;

6) балаларда лидерлык сыйфатлары формалаштыру;

7) мәктәпкәчә яшьтәге балаларны шәһәр һәм республика конкурсларында, чараларында катнашуга әзерләү.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста шәһәр муниципаль МББУнең татар телен белә торган 5-7 яшьлек тәрбияләнүчеләре катнаша ала.

4. Конкурста катнашу ирекле.

5. Конкурста катнашу өчен кандидатларны тәкъдим итү МББУ коллективлары яки ата-аналар тарафыннан башкарылырга мөмкин.

6. Конкурсның оештыручылары – Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге, Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» 1 нче балалар бакчасы – баланы үстерү үзәге» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм составы Башкарма комитет карары белән расланган оештыру комитеты.

7. Оештыру комитеты һәрбер турда конкурс үткәрүгә нәтиҗәләр ясый, шулай ук күпчелек тавыш буенча конкурсның җиңүчеләрен раслый.

3 бүлек. Конкурс үткәрүнең тәртибе.

8. Конкурс өч турда үткәрелә.

9. I тур 2020 елның 18 мартыннан 2020 елның 20 мартына кадәр үткәрелә:

2020 елның 18 мартында 09.00 сәгатьтә – 90 нчы МББУда:

1, 3, 5, 6, 11, 13, 24, 25, 42, 43, 48, 58, 84, 85, 89, 90, 99 нчы МББУ;

2020 елның 19 мартында 09.00 сәгатьтә - 126 нчы МББУда:

2, 4, 15, 19, 23, 32, 47, 57, 63, 87, 88, 91, 101, 107, 112, 113, 116, 119, 124, 125, 126 нчы МББУ;

2020 елның 20 мартында 09.00 сәгатьтә – 114 нче МББУда:

7, 18, 29, 31, 35, 39, 41, 44, 45, 46, 53, 56, 60, 61, 78, 80, 83, 94, 98, 104, 111, 114, 115, 122, 123 нче МББУ;

2020 елның 18 мартында 09.00 сәгатьтә - 22 нче МББУда:

22, 27, 33, 36, 37, 38, 55, 59, 67, 68, 69, 70, 71, 74, 76, 77, 79, 81, 93, 95, 100, 102, 117 нче МББУ;

2020 елның 19 мартында 09.00 сәгатьтә – 14 МББУда:

10, 12, 14, 17, 20, 21, 26, 49, 64, 72, 73, 75, 92, 96, 97, 105, 106, 110, 120 нче МББУ;

2020 елның 20 мартында 09.00 сәгатьтә – 8 нче МББУда:

8, 9, 16, 28, 30, 34, 40, 50, 51, 52, 54, 62, 65, 66, 82, 86, 103, 108, 109, 118, 121 нче МББУ.

Конкурсның I тур программасы өч өлештән тора:

1) визит карточкасы, монда катнашучы индивидуаль формада яки МББУ тәрбияләнүчеләре катнашында үзе, гаиләсе турында, татар теленә мөнәсәбәте, үзенең шөгыльләре, шулай ук татар халкының тарихи, рухи традицияләре һәм мәдәнияте турында сөйли (чыгыш 3 минутка кадәр);

2) теләсә кайсы жанрдагы сәнгать номеры, 3 минутка кадәр.

Конкурсантларның сәнгать номеры Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуга яисә «КАМАЗ» автозаводы төзелә башлауга 50 ел тулуга багышланган тематикадагы эчтәлектә булырга тиеш (сайлап алына);

3) татар телендә интерактив уен.

Конкурсның I туры нәтиҗәләре буенча МББУнең һәр төркеменнән конкурсның II турында катнашу өчен 5 малай һәм 5 кыз чыгарыла.

10. II тур Яр Чаллы шәһәре районнары буенча 2020 елның 25 мартыннан 2020 елның 27 мартына кадәр үткәрелә:

- 2020 елның 25 мартында 09.00 сәгатьтә 42 нче МББУда – Комсомол районы;
- 2020 елның 16 мартында 09.00 сәгатьтә 94 нче МББУда – Үзәк районы;
- 2020 елның 27 мартында 09.00 сәгатьтә 72 нче МББУда – Автозавод районы.

11. Балаларның чыгышларын бәяләүнең төп критерийлары:

1) татар телен белү;
2) сәхнәдә үзен тота белү;
3) актерлык осталыгы һәм сәхнә сөйләме дәрәҗәсе;
4) индивидуальлек;
5) музыканың, җырның, шигырьнең эчтәлеге балаларның яшенә туры килүе;
6) концерт номерларының әзерлеге һәм тамашалыгы;
7) костюмнарның эстетик ягы.

Конкурсантларның чыгышлары бәяләгән вакытында номерлар башкарганда файдаланылган реквизит бәяләнмәячәк.

II тур нәтиҗәләре буенча җиңү яулаган 5 малай һәм 5 кыз конкурсның финалында катнашу өчен чыгарыла.

12. Финалда катнашучылар вокал, хореография буенча куючы белән репетицияләрдән торган махсус әзерлек үтәләр.

Финалист экранда үзе һәм үзенең шөгыле турында презентация тәкъдим итә.

Конкурсның финалы 2020 елның 17 апрелендә «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесенең театр залында шоу – программа рәвешендә үтәчәк.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

13. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан әлеге нигезләмәнең 11 пункты нигезендә билгеләнгән критерийлар нигезендә биш баллы система буенча бәяләнә. Оештыру комитетының карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

14. Иң күп балл җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танyла.
15. Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:
- «Татар малае - 2020»;
- «Татар кызы - 2020»;
- «Милли традицияләрдә тәрбияләнгән малай (кыз)»;
- «Иң тырыш малай (кыз)»;
- «Иң талантлы малай (кыз)»;
- «Иң матур сәхнә образы өчен».
16. Конкурсның җиңүчеләре дипломнар һәм призлар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 13 февралендәге
661 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татар малае», «Татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар) муниципаль конкурсына әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 2. | Кашапов Нәркиз Венер улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгының беренче урынбасары |
| 3. | Гамманова Илүсә Өлфәт кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» 1 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 13 февралендәге
661 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Татар малае», «Татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар)
муниципаль конкурсын үткәрү буенча чыгымнар
сметасы

| Исеме | Саны, бер. | Берәмлек бәясе, сум. | Гомуми сумма, сум. |
|---|---|---|---|
| Конкурс финалистларына призлар (уенчыклар) | 10 | 2400,00 | 24 000,00 |
| Конкурс финалистларына булышучы балаларга призлар (уенчыклар) | 70 | 500,00 | 35 000,00 |
| Дипломнар | 20 | 20,00 | 400,00 |
| Дипломнар өчен рамкалар | 10 | 150,00 | 1 500,00 |
| Сәхнәне бизәү өчен гелийлы шарлар | 100 | 50,00 | 5 000,00 |
| Радиомикрофоннар өчен туендыру элементлары | 20 | 35,00 | 700,00 |
| Флэш-карта | 10 | 340,00 | 3 400,00 |
| | | барлыгы: | 70 000,00 |

Барлыгы: 70 000,00 (җитмеш мең) сум 00 тиен.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова